КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 16 декабрь г.Казань № 1146

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Украина территориясендә, шулай ук максималь һәм уртача дәрәҗәдә чара күрү кертелгән Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә даими яшәгән, торак урыннарны ташлап китәргә мәҗбүр булган һәм Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларны урнаш-тыруга һәм туклануга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен оешмаларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 20 май, 479 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Украина территориясендә, шулай ук максималь һәм уртача дәрәҗәдә чара күрү кертелгән Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә даими яшәгән, торак урыннарны ташлап китәргә мәҗбүр булган һәм Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларны урнаш-тыруга һәм туклануга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен оешмаларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 20 май, 479 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 25 август, 896 нчы, 2023 ел, 21 гыйнвар, 29 нчы, 2023 ел, 23 февраль, 179 нчы, 2023 ел, 14 август,

974 нче, 2024 ел, 7 май, 312 нче, 2024 ел, 29 октябрь, 935 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:https://login.consultant.ru/link/?req=doc&base=RLAW363&n=165359

исемендә:

«оешмаларга» сүзеннән соң «һәм индивидуаль эшкуарларга» сүзләрен өстәргә;

«чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау)» сүзләрен «чыгымнарны каплау» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта:

«оешмаларга» сүзеннән соң «һәм индивидуаль эшкуарларга» сүзләрен өстәргә;

«чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау)» сүзләрен «чыгымнарны каплау» сүзләренә алмаштырырга;

Әлеге карар белән расланган Украина территориясендә, шулай ук максималь һәм уртача дәрәҗәдә чара күрү кертелгән Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә даими яшәгән, торак урыннарны ташлап китәргә мәҗбүр булган һәм Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларны урнаштыруга һәм туклануга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен оешмаларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан субсидия бирү тәртибен яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлгән).

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 20 май, 479 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 16 декабрь, 1146 нчы
карары редакциясендә)

Украина территориясендә, шулай ук максималь һәм уртача дәрәҗәдә чара күрү кертелгән Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә даими яшәгән, торак урыннарны ташлап китәргә мәҗбүр булган һәм Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларны урнаштыруга һәм туклануга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен оешмаларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан субсидия бирү тәртибе

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга, гомуми таләпләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук күрсәтелгән субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар алучыларны товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә һәм сайлап алуны уздыруга физик затларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм әлеге Тәртипкә кушымтада күрсәтелгән оешмаларга һәм индивидуаль эшкуарларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан Украина территориясендә, шулай ук Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 19 октябрендәге 756 номерлы Указы белән бәйле рәвештә Россия Федерациясе субъектларында гамәлгә ашырыла торган чаралар турында» 2022 елның 19 октябрендәге 757 номерлы Указы нигезендә максималь һәм уртача җавап бирү дәрәҗәсе кертелгән Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә даими яшәүче, торак урыннарын калдырып китәргә мәҗбүр булган һәм Татарстан Республикасында вакытлыча урнаштыру һәм тукландыру пунктларында урнашкан (булган) Россия Федерациясе гражданнарын, чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны урнаштыруга һәм тукландыруга бәйле чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү механизмын билгели (алга таба - субсидия, мөрәҗәгать итүче, чара, торак урыннарын калдырып китәргә мәҗбүр булган һәм Татарстан Республикасы территориясенә килгән гражданнар).

1.2. Субсидия бирүнең максаты - торак урыннарын ташлап китәргә мәҗбүр булган һәм Татарстан Республикасы территориясенә килгән гражданнарга карата чараларны оештыруга һәм уздыруга бәйле чыгымнарны каплау.

1.3. Әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатка каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын төп бүлүче булып аңа, бюджет акчаларын алучы буларак, Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә тиешле финанс елына субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә күчерелгән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба - Министрлык) тора.

1.4. Субсидия турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

## II. Субсидия бирүнең шартлары

2.1. Субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлешләре:

торак урыннарын калдырып китәргә мәҗбүр булган һәм Татарстан Республикасы территориясенә килгән гражданнарның туклану хезмәтләре өчен түләү;

торак урыннарын калдырып китәргә мәҗбүр булган һәм Татарстан Республикасы территориясенә килгән гражданнарның яшәү хезмәтләре өчен түләү.

2.2. торак урыннарын калдырып китәргә мәҗбүр булган һәм Татарстан Республикасы территориясенә килгән гражданнарны урнаштыру әлеге Тәртипкә кушымтада күрсәтелгән базаларында Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм тукландыру пунктлары урнашкан оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар исемлеге нигезендә гамәлгә ашырыла.P191

2.3. Мөрәҗәгать итүче субсидия бирүгә заявканы (алга таба - заявка) карау датасына һәм субсидия бирү турында килешү төзү датасына (алга таба - Килешү) түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 процентан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

алар турында экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

Берләшкән Милләт Оешмасы уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында Берләшкән Милләт Оешмасының Куркынычсызлык Советы яки Берләшкән Милләт Оешмасының Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

бу Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максат өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмаска;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты түгел;

бердәм салым исәбендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы булмау яисә Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмый;

башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы юк (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

мөрәҗәгать итүче юридик зат үзгәртеп оештыру (башка юридик затның хезмәт күрсәтүчесенә кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмавын, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәвын, мөрәҗәгать итүче эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмавын, ә индивидуаль эшкуар булган мөрәҗәгать итүче үз эшчәнлеген индивидуаль эшкуар буларак туктатмавын;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки юридки зат булган мөрәҗәгать итүченең баш бухгалтеры (булганда) турында, индивидуаль эшкуар турында мәгълүматлар булмау;

2.4. Мөрәҗәгать итүче Министрлыкка, чыгымнарны каплау максатларында заявка бирү өчен Министрлыктан тәкъдимнәр кергән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә заявка тапшыра.

2.5. Заявкада түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

а) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Украина территориясендә һәм максималь һәм уртача дәрәҗәдә чара күрү кертелгән Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә даими яшәгән, торак урыннарны ташлап китәргә мәҗбүр булган һәм Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларны урнаштыру һәм туклану чыгымнарын каплау турында» 2022 ел, 30 апрель, 406 нчы карары белән билгеләнгән форма буенча торак урыннарын калдырып китәргә мәҗбүр булган һәм

Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган затлар исемлеге;

б) мөрәҗәгать итүче турында мәгълүмат:

тулы һәм кыскартылган исеме (юридик затлар өчен);

индивидуаль эшкуарл фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);

салым түләүченең идентификация номеры;

төп дәүләт теркәү номеры;

юридик затның адресы (юридик зат өчен), теркәлү адресы (индивидуаль эшкуар өчен);

элемтәгә керү өчен телефон номеры, почта адресы һәм юридик әһәмиятле хәбәрләр җибәрү өчен электрон почта адресы;

юридик зат җитәкчесе турында мәгълүмат (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), вазыйфасы, телефоны);

юридик зат җитәкчесе вәкаләтләрен раслый торган документлар күчермәләре;

субсидияне күчерү өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә счетлар турында, шулай ук Килешүне имзалауга вәкаләтле зат турында мәгълүмат;

а) гамәлгә кую документларының күчермәләре;

г) җитәкче һәм баш бухгалтер (булган очракта) кул куйган, мөһер белән беркетелгән (булган очракта) чараны оештыруга һәм уздыруга чыгымнар сметасы;

д) әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында җитәкче тарафыннан кул куелган белешмә кәгазе (ирекле формада);

е) чараларны оештыруга һәм уздыруга бәйле фактта тотылган чыгымнарны раслаучы документларның җитәкче кул куйган, мөһер белән беркетелгән (булган очракта) күчермәләре;

ж) җитәкче һәм баш бухгалтер (булган очракта) тарафыннан имзаланган, мөһер белән беркетелгән (булган очракта) башкарылган чыгымнарны раслый торган чараларны оештыру һәм уздыру өчен кирәкле товарлар китерүгә (хезмәтләр күрсәтүгә) чит оешмалар белән төзелгән шартнамәләрнең, түләү һәм башка документларның (күрсәтелгән хезмәтләр актлары, счетлар, счетлар-фактуралар, товар-транспорт йөкләмәләре, түләү йөкләмәләре, керем һәм чыгым ордерлары) күчермәләре.

Заявкада булган мәгълүматның һәм документларның тулылыгы һәм дөреслеге өчен, шулай ук аларны вакытында тапшыру өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә мөрәҗәгать итүче җаваплы була.

Документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә тапшырыла.

Заявка һәм аңа теркәлә торган документлар бер папкага (том) тегелгән, һәр битенә номерлар сугылган, җитәкченең үз имзасы белән имзаланган һәм мөһер белән (булган очракта) таныкланган булырга тиеш.

Һәр документ төгәл итеп басылган булырга тиеш. Чистартулар һәм төзәтүләр рөхсәт ителми, моңа мөһер белән беркетелгән (булган очракта) һәм җитәкченең үз имзасы белән таныкланган төзәтмәләр керми.

Бирелә торган мәгълүматларның дөреслеге өчен мөрәҗәгать итүче Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

2.6. Мөрәҗәгать итүче үз теләге белән түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

юридик затны дәүләт теркәве турында таныклык күчермәсен йә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрын теркәү кәгазе күчермәсен (юридик затлар өчен) яки шәхси эшкуарны дәүләт теркәве турында таныклык күчермәсен йә Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрын теркәү кәгазе күчермәсен (индивидуаль эшкуарлар өчен);

салым органында исәпкә кую турында документ күчермәсен;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан (юридик затлар өчен) яисә Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан (индивидуаль эшкуарлар өчен) өземтә.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан бу пунктта күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, Министрлык аларны ведомствоара мәгълүмат алышу тәртибендә соратып ала.

2.7. Министрлык электрон хезмәттәшлек кысаларында Министрлыкның файдалану мөмкинлеге булган дәүләт мәгълүмат системаларында тиешле мәгълүмат булган очракта Министрлык сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган документларны тапшыруны таләп итәргә хокуклы түгел, мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән документларны һәм мәгълүматны үз инициативасы белән Министрлыкка тапшырырга әзер булган очрактан тыш.

2.8. Заявка Министрлык тарафыннан заявкаларны теркәү журналына кергән көнне теркәлә.

## III. Килешү төзү тәртибе

3.1. Министрлык заявка теркәлгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә мөрәҗәгать итүчене, шулай ук ул тапшырган документларны әлеге Тәртипнең 2.3 һәм 2.5 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәү предметына тикшерә, субсидия бирү турында яисә субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә, мөрәҗәгать итүченең электрон адресына кабул ителгән карар турында хәбәр җибәрә, ә субсидия бирү турында карар кабул ителгән очракта - «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында (алга таба - «Электрон бюджет» системасы) Килешү проектын теркәп.

3.2. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

мөрәҗәгать итүченең бу Тәртипнең 2.3 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

Үзәк тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 2.5 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

әлеге Тәртипнең 2.4 пункты нигезендә заявкалар бирү өчен билгеләнгән вакыт узганнан соң мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза бирү;

мөрәҗәгать итүче тапшырган мәгълүматның дөрес булмау фактын билгеләү.

3.3. Субсидия Министрлык һәм мөрәҗәгать итүче арасында «Электрон бюджет» системасында электрон документ рәвешендә Татарстан Республикасы

Финанс министрлыгы билгеләгән бертип форма нигезендә төзелгән һәм һәр як исеменнән эш итәргә хокукы булган затларның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имза салынган Килешү нигезендә бирелә.

бу Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән, элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары Министрлыкка киметелгән очракта, Килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча Килешүгә ирешеп булмаганда килешүне өзү турында, субсидияне Килешүдә билгеләнгән күләмдә бирү мөмкин булмавына китерә торган шарт Килешүгә кертелә.

Килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкинлеге булмауга китерә торган бюджет йөкләмәләренең Министрлыкка элек җиткерелгән лимитлары кимегән очракта Килешүгә Килешүнең яңа шартларын килештергәндә яисә яңа шартлар буенча килештерелмәгәндә Килешүне өзү турында өстәмә килешү төзелә.

Кирәк булуга карап, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

3.4. Юридик зат булган субсидия алучыны кушылу, кушу яисә үзгәртеп кору рәвешендә үзгәртеп төзегәндә, килешүгә, хокук варисы булган юридик затны килешүдә күрсәтеп, мәҗбүри рәвештә затны алмаштыру өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәрешләр кертелә.

3.5. Мөрәҗәгать итүче Министрлык Килешүне «Электрон бюджет» системасында төзегән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә мөрәҗәгать итүче исеменнән «Электрон бюджет» системасы аша эш итәргә хокукы булган затларның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән Килешүне имзаларга тиеш.

Мөрәҗәгать итүче Килешү төзүдән читләшкән дип таныла, ә мөрәҗәгать итүчегә субсидия бирү турындагы карар, әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән вакытта, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Килешүгә «Электрон бюджет» системасы аша имза салынмаган очракта, юкка чыгарылган дип санала.

3.6. i-нче мөрәҗәгать итүче өчен субсидиянең исәп-хисап күләме ($C_i$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C_i = K_i \times N_i \times M_i,$$

монда:

$K_i$ - торак урыннарын калдырып китергә мәҗбүр булга, Татарстан Республикасы территориясенә килгән һәм вакытлыча урнаштыру һәм тукландыру пунктларындагы (урнашкан) гражданнар саны;

$N_i$ - торак урыннарын калдырып китергә мәҗбүр булга, Татарстан Республикасы территориясенә килгән һәм вакытлыча урнаштыру һәм тукландыру пунктларындагы (урнашкан) гражданнарның булу дәвамлылыгы (әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар исемлеге буенча), көн;

$M_i$ - вакытлыча урнаштыру һәм тукландыру пунктында тору чыгымнары, бер кешегә урнаштыру һәм туклану чыгымнары тәүлегенә 1 328 сумга кадәр итеп, шул исәптән бер кешегә урнаштыру өчен тәүлегенә 913 сумга кадәр һәм бер кешегә тукландыру өчен чыгымнар тәүлегенә 415 сумга кадәр күләмдә .

3.7. Министрлык, субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң килә торган 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, субсидияне Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә кредит оешмаларында мөрәҗәгать итүче ачкан исәп-хисап яки корреспондентлык счетына күчерә.

## IV. Субсидия бирү нәтиҗәсе һәм хисапка карата таләпләр

4.1. Субсидия бирү нәтиҗәсе - мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге Тәртипкә кушымтада күрсәтелгән Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм тукландыру пунктлары урнашкан оешмаларда һәм индивидуаль эшкуарларда булу чорына торак урыннардан мәҗбүри рәвештә килгән һәм Татарстан Республикасы территориясенә килгән гражданнарның санын урнаштыру һәм тукландыру субсидиясен бирү көненә 100 процент күләмендә гамәлгә ашыру.

4.2. Мөрәҗәгать итүче «Электрон бюджет» системасы аша субсидия бирелгән көннән алып 25 календарь көннән дә соңга калмыйча субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткечләренә ирешү турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән килешүнең бертип рәвешенә кушып бирелә торган форма буенча хисап тапшыра.

4.3. Министрлык мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган әлеге Тәртипнең 4.2 пунктында каралган хисапны «Электрон бюджет» системасында алган көннән алып биш эш көне эчендә тикшерә һәм хисапны кабул итү яки кире кагу турында карар кабул итә.

Хисапны кире кагу өчен нигезләр:

хисапта аларны тапшыру өчен хисапның бертип формаларында каралган белешмәләр тулы күләмдә булмау, һәм (яисә) мондый белешмәләр хисапта тулы күләмдә бирелмәү;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан хисапта бирелгән мәгълүматның дөрес булмау фактын билгеләү.

4.4. Әлеге Тәртипнең 4.2 пунктында күрсәтелгән Министрлыкка тапшырыла торган хисапның дөреслеге өчен җаваплылык мөрәҗәгать итүчегә йөкләнә.

## V. Субсидияләр бирү шартларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыруга таләпләр һәм аларны бозган өчен җаваплылык

5.1. Субсидия мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән алып календарь көннәрендә хисаплана торган 30 көн эчендә кире кайтарылырга тиеш:

субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан бозылган очракта, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча да – тулы күләмдә;

субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешмәгәндә - субсидия бирү нәтиҗәсенең ирешелмәгән күрсәткеченә пропорциональ рәвештә билгеләнә торган күләмдә.

5.2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан бу Тәртипнең 5.1 пунктында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару срогы бозылганда, Министрлык субсидияне кире кайтару срогы чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә түләттерү буенча чаралар күрә.

5.3. Министрлык мөрәҗәгать итүченең субсидия бирү шартларын һәм тәртибен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә) үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

Украина территориясендә, шулай ук максималь һәм уртача дәрәҗәдә чара күрү кертелгән Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә даими яшәгән, торак урыннарны ташлап китәргә мәҗбүр булган һәм Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларны урнаштыруга һәм туклануга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен оешмаларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан субсидия бирү тәртибенә кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә базаларында Украина территориясендә, шулай ук максималь һәм уртача дәрәҗәдә чара күрү кертелгән Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә даими яшәгән, торак урыннарны ташлап китәргә мәҗбүр булган Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар өчен вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктлары урнашкан оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар исемлеге

| Т/с | Вакытлыча урнаштыру һәм туклану пункты урнашкан муниципаль берәмлек исеме | Базасында вакытлыча урнаштыру һәм туклану пункты урнашкан оешма (индивидуаль эшкуар) исеме | Базасында вакытлыча урнаштыру һәм туклану пункты урнашкан оешма (индивидуаль эшкуар) почта адресы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Чаллы шәһәре | «КАМАЗжилбыт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | Яр Чаллы шәһ., Академик Рубаненко ур., 6 нчы й. |
| 2. | Чаллы шәһәре | «Жемчужина» шифаханәләр һөнәр берлекләре дәвалау-профилактика хосусый учреждениесе | Чаллы шәһ., Мелекесская ур., 1 й. |
| 3. | Казан шәһәре | «КВАРТ» Кама-Идел резинотехника акционерлык җәмгыяте» акционерлык җәмгыяте («КВАРТ» акционерлык | Казан шәһ., Техник ур., 25 нче й. |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | җәмгыятенең кунакханә-торак комплексы) | |
| 4. | Казан шәһәре | «Ливадия-Татарстан» шифаханәләр һөнәр берлекләре дәвалау-профилактика хосусый учреждениесе | Казан шәһ., Себер тракты ур., 192 нче а/т |
| 5. | Казан шәһәре | Индивидуаль эшмәкәр Әбүшахманова Гөлнара Рафаил кызы («Второй Дом» кунакханәсе) | Казан шәһ., Калинин ур., 60 й., 53 нче ф. |
| 6. | Казан шәһәре | «Экспресс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте («Экспресс» хостеле) | Казан шәһ., Сәетгалиев ур., 6 й. |
| 7. | Казан шәһәре | Индивидуаль эшмәкәр Гарбуз Михаил Иосифович («Отель Стрела») | Казан шәһәре, Рәүис Гәрәев ур., 80 й. |
| 8. | Алабуга муниципаль районы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (Алабуга институты (филиал)) | Казан шәһ., Кремль ур., 18 й. |
| 9. | Зеленодольск муниципаль районы | «Васильевский» шифаханәләр һөнәр берлекләре дәвалау-профилактика хосусый учреждениесе | Зеленодольск муниципаль районы, Васильево пос., Шифаханә территориясе урамы, 1 А йорт |
| 10. | Лаеш муниципаль районы | «Санта» шифаханәсе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | Казан шәһ., Пушкин ур., 12 й. |
| 11. | Лаеш муниципаль районы | «Санта Регина» шифаханәсе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | Казан шәһ., Җиңү пр., 105 й., 4 офис |
| 12. | Биектау муниципаль районы | Казан шәһәренең «Балалар һәм яшьләр ялын, аларны сәламәтләндерүне, эш белән тәэмин итүне оештыру буенча «Ял» шәһәр үзәге» муниципаль бюджет яшьләр сәясәте учреж- | Казан шәһәре, 25 октябрь ур., 13/6 й. |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | дениесе, «Яшьләр» ел әйләнәсе сәламәтләндерү лагере (Татарстан Рес-публикасы, Биектау муниципаль районы, Березовка поселогы) | |